КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 сентябрь г.Казань № 1098

2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (撥карарга теркәләләр) расларга:
2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;
2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру күләмнәрен;
2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү)» дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны.
2. «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүнең дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт биреме үтәлешен финанс белән тәэмин итү күләменә карата 1,1132 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:
«2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 954 нче;
«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 2 сентябрь, 954 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 2 май, 557 нче;

4. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1098 нче
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | 1 елга 1 белем алучыга норматив чыгымнар, сум | | |
|---|---|---|---|
| | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм шуннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | 7 851 | 14 539 | 17 447 |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1098 нче
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан өстәмә гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру күләмнәре

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Белем алучылар саны, кеше | | |
|---|---|---|---|
| | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм шуннан соңгы еллары |
| Сәнгать-эстетик | 40 | 54 | 340 |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1098 нче
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан «дәүләт (муниципаль) милкендәге мөлкәтне карап тоту (эксплуатацияләү)» дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар

| «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе милкендәге мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнар, мең кв.метрга сум | «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе милкендәге мөлкәтне карап тотуга (эксплуатацияләүгә) дәүләт эшен башкару күләме, мең кв.метр |
|---|---|
| 2 059 242,0 | 1,993 |

___